ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 октябрь, 2019 ел № 33/14

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 31/13 санлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында Кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 28, 48 маддәләре нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1.Шәһәр Советының 2008 елның 18 апрелендәге «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 31/13 санлы Карарына (Шәһәр Советының 2009 елның 9 апрелендәге 40/23, 2012 елның 20 сентябрендәге 21/11, 2013 елның 29 августындагы 26/15, 2015 елның 22 октябрендәге 2/19, 2016 елның 15 декабрендәге 13/11 санлы, 2018 елның 10 августындагы 26/14 Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1)19 пунктның 4-7 пунктчаларын көчен югалткан дип танырга;

2)20 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20.Муниципаль хезмәткәрләргә бирелүче гарантияләрне бирү тәртибе һәм шартлары шәһәр Хакиме тарафыннан билгеләнә.».

2.Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советыныңң регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ